**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Аулаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«14» апрель 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 28 мартында түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Аулаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау Үзәк урамында)»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау Үзәк урамында)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 76 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 39 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 39 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Аулаш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Аулаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау Үзәк урамында)»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау Үзәк урамында)».

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иштирәк авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы Г.С.Гарифуллина